УДК 81'374

*Г.Х. Гыйләҗетдинова*

# XV–XVII ГАСЫРЛАР РУС ТЕЛЕНДӘГЕ КӨНЧЫГЫШ АЛЫНМАЛАРЫ СҮЗЛЕГЕН ОЕШТЫРУ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

В статье представлена концепция «Словаря восточных заимствований XV–XVII вв.», относящегося к историческим словарям филологического типа. Источниковой базой Словаря выступают памятники письменности разножанрового характера – повести, пьесы, официально-деловые тексты, описи имущества, хожения, эпистолярные источники, конфессиональная литература и др. Выявляется словообразовательный потенциал восточных слов в русском языке XV–XVII вв., определенную часть которых составляют лексические единицы тюркского и татарского происхождения. Определены принципы описания выявленных дериватов в подготовленном к публикации словаре восточных заимствований исследуемого периода. Подчеркивается, что неодинаковая словообразовательная активность ориентализмов обусловлена как особенностями самих заимствованных лексем, так и адаптационными возможностями языка-рецептора.

**Ключевые слова:** ориентализмы, язык-рецептор, словообразовательный потенциал, русский язык XV–XVII вв., словарь восточных заимствований.

The article presents the concept of the “Dictionary of Eastern Borrowings of the 15th–17th Centuries”, which belongs to historical dictionaries of the philological type. The source base of the Dictionary is written monuments of different genres – stories, plays, official and business texts, inventories of property, travels, epistolary sources, confessional literature, etc. The word-formation potential of Eastern words in the Russian language of the 15th–17th centuries is revealed, a certain part of which are lexical units of Turkic and Tatar origin. The principles of describing the identified derivatives in the Dictionary of Eastern Borrowings of the period under study, prepared for publication, are determined. It is emphasized that the unequal word-formation activity of Orientalisms is due to both the peculiarities of the borrowed lexemes themselves and the adaptive capabilities of the receptor language.

**Keywords:** orientalisms, receptor language, word-formation potential, Russian language of the 15th–17th centuries, Dictionary of Eastern borrowings.

Хәзерге тарихи лексикография фәне хәл итәсе актуаль мәсьәләләрнең берсе булып билгеле бер өлешен төрки һәм татар чыгышлы лексик берәмлекләр тәшкил иткән борынгы рус чоры Көнчыгыш алынмалары сүзлеген төзү тора. Бүгенге көндә Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикография бүлегендә «XV–XVII гасырлар рус телендәге Көнчыгыш алынмалары сүзлеге» басмага әзерләнә. Тикшерелә торган чор ориентализмнарының тулы җыелмасын төзегәндә, төрле жанрларга караган язма истәлекләр кыйммәтле чыганак ролен үти.

Сүзлекнең бурычы – рус милли әдәби теле формалашкан чорда Көнчыгыш алынмаларының һәм алардан ясалган сүзләрнең яшәеш үзенчәлекләрен билгеләп, аларны анализлана торган чыганаклар төркемендә аерып күрсәтү.

Жанры ягыннан хезмәтне филологик типтагы тарихи сүзлек дип атарга мөмкин. Сүзлек 1600 гә якын лексеманы (алынмалар һәм сүзләрнең гомуми санының яртысын диярлек тәшкил иткән шул алынмалардан ясалма номинацияләрне) һәм 350 дән артык сылтама сүзне (сүзлектә фонетик, сүзьясалыш, морфологик вариантлар өчен сылтамалы юллар бар) колачлый. Ул алфавит тәртибендә төзелә.

Сүзлек телдә безнең көннәргә кадәр сакланган лексемаларны (амбар, бахрома, казна, казначей, нефть, очаг) һәм бүгенге көндә кулланылыштан төшеп калган алынмаларны үз эченә ала. Мәсәлән: (*алафа* [тур. ülüfe ‘жалованье’ от араб. ‘ulüfa ‘жалованье, плата’] ‘награда, дар; жалованье; оброк’, *алман* [шор., леб., саг., чул. alban ‘дань, подать’ (из монг. alban, калм. alwn̥)] ‘налог, собираемый в пользу правителей местных народов Сибири’, *бехтерец* [из монг. bekter ‘доспех из металлических дощечек’] ‘панцирь из металлических пластинок’).

Алынма сүзләрне анализлау өчен, XV–XVII гасырларга караган төрле язма истәлекләргә мөрәҗәгать ителә. Галимнәр фикеренчә, алар рус теленең халыклашкан әдәби-язма вариантында иҗат ителгәннәр (В.В. Виноградов, Б.А. Ларинин, В.В. Колесов һ. б.). Анализланган текстлар арасында (150 дән артык язма истәлек) түбәндәгеләр бар: 1) публицистик текстлар (И. Пересветов, патша Явыз Иван (XVI гасыр), протопоп Аввакум (XVII гасыр) һ. б. әсәрләре); 2) XV–XVII гасырлар рус повестьлары; 3) пьесалар («Артаксерксово действо» (1672), «Юдифь» (1674), «Баязет и Тамерлан» (1674–1675 ) һ. б.).

Файдаланылган чыганаклар арасында чит илләрне тасвирлауга багышланган сәяхәтнамәләр («Хожение инока Зосимы» (1419–1422); Афанасий Никитинның «Хожение за три моря» (1466–1472); «Хожение купца Василия Познякова по святым местам Востока» (1558–1561) һ. б.) аерым урын алып тора. Әлеге әсәрләрдә шәркый чыгышлы экзотик лексика киң кулланыла. Бу сәяхәтнамә жанры үзенчәлекләре белән аңлатыла. Чыганаклар арасына шулай ук рус теленең милли чор әдәби нормалары, аның сүзлек составы, шул исәптән Көнчыгыш фондының формалашу процессын тикшерүдә зур әһәмияткә ия булган эш кәгазьләре текстлары да кертелде: рәсми эш кәгазьләре («Акты Московского государства» (1571–1644), таможня кенәгәләре, илчеләрнең отчёт-көндәлекләре).

Эш кәгазьләре репрезентантлары сыйфатында эпистоляр текстлар («Частная переписка князя П.И. Хованского, его семьи и родственников» (XVII гасыр), «Письма царя Михаила Федоровича» (1619–1631) һ. б.) тикшерелде. Аларда Мәскәү дәүләтендәге төрле халык катлауларының шәхси тормышы һәм эшчәнлеге турында кыйммәтле мәгълүматлар бар.

Чыганакларның шактый зур төркемен халык сөйләм теле тарихы буенча истәлекләр тәшкил итә. Алар эш кәгазьләрендә һәм көндәлек тормышта Көнчыгыш сүзләренең киң үзләштерелүен һәм таралуын күрсәтә. Шундыйлардан «Памятники русского народно-разговорного языка XVII столетия (из фонда А.И. Безобразова)» (М., 1965), «Московская деловая и бытовая письменность XVII века» (М., 1968), «Грамотки XVII – начала XVIII в.» кебекләрне билгеләп үтәргә мөмкин.

Тарихи-этнографик пландагы кыйммәтле лексик материалны үз эченә алган текстлар аерым игътибарга лаек. Мәсәлән, патшалык итүче затлар даирәсенә караган мал-мөлкәт исемлекләре («Платье царя Бориса Феодоровича Годунова, 1589 г.», «Царская утварь и платье царя Феодора Алексеевича, 1682 г.» һ. б.). Алар төрле тематик төркемнәргә (тукыма, өс киеме, аяк киеме, көбә кием һәм кораллар, ат дирбияләре һ. б.) караган Көнчыгыш алынмаларын ачыкларга мөмкинлек бирә.

Конфессиональ әдәбият истәлекләре (изгеләрнең тәрҗемәи хәлләре, мактау сүзләре һ. б.), Көнчыгыш лексикасы бик аз тәкъдим ителүгә карамастан, иске рус телендәге төрле жанрларга караган чыганаклар аша чит тел лексик берәмлекләренең яшәешен бербөтен картина итеп күзаллый алабыз.

Чыганаклар буларак XVI гасыр – XVIII гасыр башына караган җирле эш кәгазьләрен фәнни әйләнешкә кертеп җибәргән региональ тарихи сүзлекләр файдаланыла: «Региональный исторический словарь второй половины XVI – XVIII вв. (по памятникам письменности Смоленского края)» (Смоленск, 2000), «Казанский край: словарь памятников XVI в.» (Казань, 2000), «Казанский край: словарь языка памятников первой четверти XVII в.» (Казань, 2008), «Словарь русской народно-диалектной речи в Сибири XVII – первой половины XVIII в.» (Новосибирск, 1991) һ. б. Әлеге лексикографик ядкәрләрдә рус теленең сүзлек составы тарихын тулаем яңадан торгызу өчен җитәрлек материал тупланган. Моннан тыш, рус теленең тарихи сүзлекләре (И.И. Срезневский. «Материалы для словаря древнерусского языка»; «Словарь русского языка XI–XVII вв.», «Словарь русского языка XVIII века» һ. б.), терминологик сүзлекләр (Г.Е. Кочин. «Материалы для терминологического словаря древней России») ориентализмнарның хронологиясен, рус теленә үтеп керү юлларын һәм аларның алга таба үсешен ачыклауда мөһим лингвистик чыганак булып торалар.

Әзерләнә торган Көнчыгыш алынмалары сүзлеге өйрәнелә торган чыганакларда табылган барлык Көнчыгыш сүзләрен һәм алардан ясалган лексик берәмлекләрне тулысынча тасвирлауга юнәлтелгән лексикографик тикшеренү булып тора. Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: табылган алынмаларның этимоннарын – алынма сүзнең эчке формаларын ачып бирү максаты белән баш сүздән соң этимологик белешмә бирелә.

**АРЧАКЪ (ОРЧАКЪ),** *м.* [тат. arčak ‘седельная лука’] Деревянный остов седла, седло.

Сүзлектә төрле дәрәҗәдә адаптацияләнгән Көнчыгыш алынмалары теркәлә. Барыннан да элек, фонетик, морфологик һәм семантик планда үзләштерелеп, XV–XVII гасырларда рус теле составына шактый тирән үтеп кергән саф алынма сүзләр билгеләнә: аманатъ, амбаръ, артель, аршинъ, атаманъ, бахматъ, бахрома, башмакъ, войлокъ, камка, кафтанъ, набатъ, серьги һ. б. Мондый лексика өйрәнелә торган чорда сүз ясалышы активлыгы белән аерылып тора. Мәсәлән, атаман – атаманишка, атаманов, атаманский, атаманство; кирпич – кирпичик, кирпичник, кирпичный, кирпищик һ. б.

Көнчыгыш лексикасының икенче өлешен рус теле законнары буенча төзелгән, әмма фонетик-график һәм морфологик вариативлыклары белән аерылып торган экзотик Көнчыгыш реалияләрен характерлаган сүзләр тәшкил итә. Экзотизмнар азсанлы мисалларда чагылыш таба: абызъ (абазъ, обузъ, обызъ) [тат., казах., тоб. abyz ‘ученый мулла’] ‘мөселман рухание (имам, мулла)’, амиръ һәм амира [гарәп. ‘amīr ‘хөкүмәт башлыгы, җитәкче’] ‘хөкүмәт башлыгы титулы (мөселман Шәрыгы илләрендә)’, куранъ һәм алкоранъ (олкаранъ, олкаренъ) [гарәп. al kur’ān] ‘мөселманнарның изге китабы, Коръән’ һ. б. Мондый стилистик төсмерләргә бай ориентализмнар тасвирланган күренешләрнең Көнчыгыш колоритын булдыру өчен кулланылалар, һәм аларның сүзьясалыш потенциалы чикләнгән.

Көнчыгыш сүзләренең өченче тибы текстларда үзләренең беренчел формаларында бирелгән һәм, реципиент телдә ассимиляциягә дучар ителмичә, үзләрен чит тел сүзе буларак саклап калган ясалма булмаган лексемаларны үз эченә ала. Мәсәлән: арпа [тат. arpa ‘ячмень’], раки [төр., кыпч. raky ‘водка’, гар. ‘araqy ‘финиковая водка’] ‘виноградное вино’, [тур. hälâl ‘дозволенный к применению’ (из араб. χälâl)] ‘дозволенное религиозным законом’ халялъ һ. б. Еш кына мондый чит тел сүзләренә аңлатмалар текстта бирелә. Мәсәлән: «<...> арпа, а по рускому ячмень, а иного хлеба нет» (Х. Котова, 32. 1624 г.). Әлеге төр алынмаларны сүзлеккә кертү – тикшерелә торган чыганакларда ачыкланган барлык шәркый чыгышлы лексемаларны (мөмкин кадәр) чагылдыру бурычы белән аңлатыла.

Сүзлек апеллятив лексика нигезендә төзелә, һәм анда кеше исемнәре кертелми. Сүзлеккә а) уртаклык мәгънәсендә кулланыла торган (чагыштыр: **БУХАРА,** ж. Сорт кожи); ә) тотрыклы терминологик сүзтезмәләр составына кергән (чагыштыр: **БУРМИНСКИЙ,** прил. [от тюрк. названия города Ормуз (Хормуз) – Hormuz, Hurmuz – у Персидского залива] Название жемчуга лучшего качества (подобного добываемому в Персидском заливе). ***Бурминское зерно*** – крупная, правильной формы жемчужина) географик атамалар (һәм алардан ясалган сүзләр) алына.

Сүзлектә шулай ук төрле кабиләләр һәм халыкларның исемнәре һәм алардан ясалган сүзләр китерелә:

**БОЛГАРЫ,** мн. [др.-тюрк. bulγar ‘смешанного происхождения, метис’ от bulγamak ‘мешать’] Народы, населяющие Поволжье и Прикамье.

XV–XVII гасырлар рус теленең төрле жанрларга караган истәлекләрендә безнең тарафтан табылган кайбер Көнчыгыш алынмалары һәм алардан ясалган сүзләр (инчи ‘скатный жемчуг’, дугень ‘торговая лавка’, киса ‘сумка, мешок, котомка’, курбан ‘жертва’, арбузец, казаченки, лальный ‘украшенный лалами’, мечетный, намазный, натесемничек һ. б.) «Словарь русского языка XI–XVII вв.» академик басмасында теркәлмәгән.

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: XV–XVII гасырларда рус телендә Көнчыгыш алынмалары төрле сүзьясалыш активлыгы күрсәтәләр. Ясалма булмаган Көнчыгыш лексемалары белән беррәттән, рус сүзьясалышының продуктив модельләре нигезендә сүзьясалыш морфемаларын алган ясалма ориентализмнар да зур кызыксыну тудыра. Ир-атларны ‘кешене һөнәренә карап атау’ дигән гомумиләштерелгән мәгънә белән атаганда кулланылган -ник формантлы исемләшкән ясалма сүзләр шактый зур төркем тәшкил итә. Мондый дериватларның сүзьясагыч мәгънәсе – ‘затны эш-хәрәкәтнең объекты яисә эш коралы буенча атау’: алмазник ‘шлифовальщик драгоценных камней’, кармачник ‘тот, кто делает кармаки (удочки)’, кирпичник ‘тот, кто изготовляет кирпичи’, нагарник ‘тот, кто играет на нагаре’. -ник формантлы ясалмалар белән параллель рәвештә ир-ат җенесендәге затларның -чик-/-щик- кушымчалы бер тамырлы атамалары да бирелә: алмазник – алмазщик, кирпичник – кирпищик. Хезмәттә алар аерым сүзлек мәкаләләрендә урнаштырыла. Мәсәлән:

**КИРПИЧНИКЪ (КИРПИШНИКЪ),** м. Тот, кто изготовляет кирпичи. *Кудинко Микитин* ***кирпишник***. Кн. п. Казани, 17. 1565–1568 гг.

**КИРПИЩИКЪ,** м. То же, что **кирпичникъ**. *Даточныхъ же людей въ камещики и въ* ***кирпищики*** *выбрано на Москвѣ другого сбору 20 ч. да третьего сбору 716 ч., итого 736 ч.* АМГ III, 434. 1661 г.

Сүзлектә шулай ук тасвирлау бирәмлекләре булып ачыкланган дублет формалар да урын ала, аларда кечерәйтү мөнәсәбәтләрен нейтральләштерү нәтиҗәсе буларак ясаучы һәм ясалма сүзләр синонимиясе күзәтелә: брага – бражка, ферезь ‘вид кафтана’ – ферезец, серьги – сережки һ. б. Мәсәлән:

**СЕРЬГИ,** мн. [из чагат. isirγa, ysyrγa ‘ушные подвески’, туркм., караим., кыпч., карач., балк., тат., казах., кирг. syrγa ‘серьга’] Серьги. *Святые образы и кресты* [казанцы] *преливаху* ***серьги*** *и ожерелия и мониста, и наряжаху тафья на главы своя, украшахуся* <...> Каз. ист., 76. XVI в.

**СЕРЕЖКИ,** мн. То же, что **серьги**. ***Сережки** золотые одинцы с репьи.* Сл. Каз. кр. XVI, 215. 1568 г.

Ясалма исемнәр арасында субъектив бәяләү мәгънә төсмерләренә ия булган бер төркем сүзләр аерылып тора. Биредә -к һәм -ик, -ок, -чик-, -ец- суффикслары ярдәмендә ясалган лексемаларны мисал итеп китерергә мөмкин. Әлеге кушымчалар ясалма нигезләр белән бергә кечерәйтүне, кечкенә үлчәмнәрне белдерәләр: бирюзка, колымажка, стаканчик, сургучик, тазик, ярлычок һ. б. Кечерәйтү-кимсетү маркировкалы -ишко суффиксына беткән субъектив бәяләү мәгънә төсмерләренә ия булган лексемалар предметларны (кафтанишко), хайваннарны (лошадишко), абстракт төшенчәләрне (кабалаишко) атаганда еш очрыйлар. Сүзлектә Көнчыгыш алынмаларыннан ясалган исемнәрнең стилистик мәгънә төсмерләре тиешле стилистик һәм экспрессив бизәк белән билгеләнә, мәсәлән:

**БАЗАРИШКО,** с., уменьш.-уничиж. к **базаръ**.

**КУМГАНЕЦЪ,** м., уменьш. к **кумганъ**.

Көнчыгыш чыгышлы алынма нигезләрдән ясалган сыйфатлар өйрәнелә торган чор телендә шактый күпсанлы төркемне тәшкил итә. Чыганакларда алар, нигездә, -н(ый) суффиксы ярдәмендә ясалалар. Ул хәзерге рус телендә дә, XV–XVII гасырлар телендә дә продуктив кушымчаларның берсе санала. -н(ый) суффиксы һәм аның вариантлары -ин(ый) ярдәмендә алынма нигезләр базасында предметны төрле мөнәсәбәт төрләре нигезендә тасвирлый торган сыйфатлар ясала: 1) нәрсәдәндер ясалган: изумрудный, кумачный, сафьянный; 2) нәрсә өчендер билгеләнгән: вьючный, лошадиный һ. б. Шунысы кызык: «Көнчыгыш» тукымаларының төрле сортлары атамалары сыйфат ясау өчен нигез булып хезмәт иткән предмет мәгънәле исемнәр рәтендә иң күпсанлы лексик-тематик төркемгә әверелгән: зуфь ‘шерстяная ткань’ – зуфный, кармазинъ ‘тонкое сукно красного цвета’ – кармазинный, кисея ‘легкая прозрачная ткань’ – кисейный һ. б.

Тикшерелә торган чорда күбесенчә зат мәгънәсендәге алынма исемнәрдән, аерым очракларда -ский форманты ярдәмендә ясалган адъектив ясалма сүзләр дә продуктив: атаман – атаманский, боярин – боярский. Аерым очракларда хайван атамалары җәлеп ителә: обезьяна – обезьянский һ. б. -ский формантлы сыйфатлар ясалганда, этник атамалар да мотивлаштыручы исемнәр була ала: бесермен(ин) – бесерменский, магметан(ин) – магметанский. Сүзьясалыш вариантлары һәм ясалма адъективларның дублетлары сүзлектә аерым мәкаләләр белән бирелде. Мәсәлән:

**АМАНАТНЫЙ,** прил. к **аманатъ**. *Порозжее место что были Никона монаха кели а после* ***аманатнои*** *двор.* Сл. Смол. кр., 23. 1673 г.

**АМАНАТСКИЙ (АМАНАЦКИЙ),** прил. к **аманатъ**. *А что, государь, дано нам, холопем твоим, твово государеву товару*

*<...> и* ***аманацково*** *корму <...> – и нам, холопем твоим, тот твой государев товар и* ***аманацкий*** *корм велено розложити на два зимов(ь)я.* Сл. Мангаз. пам., 28. 1636 г.

Исемнән ясалган сыйфатлар аерым сүзлек мәкаләләрендә бирелде, чагыштыр:

**ЖЕМЧУЖНОЕ,** с. В знач. сущ. Украшение из жемчуга. И привезено съ собою.

Сыйфатлардан ясалган рәвешләр сыйфатка бирелгән сүзлек мәкаләсендә китерелде. Мәсәлән:

**БЕСКАБАЛЬНЫЙ,** прил. <...> **Бескабально,** нареч. Без документа (кабалы), подтверждающего акт сделки.

Ясалма фигыльләрне тасвирлаганда, сүзлектә *-ти (-тися)* инфинитив формасы нигез итеп алынды.

**ИСХАРЧИТИ.** Истратить, израсходовать.

Аерым очракларда эш-хәрәкәтнең беренчел фигыльгә карата күп тапкыр булуына күрсәтмә бирелә:

**БРАЖНИЧИВАТИ (БРАЖНЕЧЕВАТИ).** Многокр. к **бражничати**.

Көнчыгыш сүзләреннән ясалган фигыль номинацияләре аз. Алар – күбесенчә суффикслы ясалма сүзләр. Фигыльләр алынма исемнәрдән түбәндәге суффикслар ярдәмендә ясала: -и- (дуванити ‘делить добычу, жалованье’, караулити), -ова-/-ева- (кочевати, сеунчевати ‘сообщать радостную весть’), -ива- (кабаливати ‘обращать в кабального холопа’). Җансыз исемнәрнең нигезләреннән ясалган вербаль ясалмаларның күбесе терминологик мәгънәләрне үстерә: алмазити ‘шлифовать (о драгоценных камнях)’, бархатити ‘вышивать выпуклым рисунком’ һ. б. Мәсәлән, сүзлектә:

**ТЕСМИТИ.** Украшать тесьмой. *Два лука Едринские поѣзжены <...> У одного каймы лазоревы, тетива шолкова,* ***тесмена*** *розными шолки.* Оруж. Мих. Фед., 59. 1640 г.

Шулай итеп, Көнчыгыш сүзләре, XV–XVII гасырлар рус теле системасында ясагыч нигезләр сыйфатында кулланылып, рецептор телдә алынмаларның лексик-семантик үзләштерелеш дәрәҗәсенә һәм Көнчыгыш лексемаларының үз семантик, грамматик үзенчәлекләренә бәйле булган төрле сүзьясалыш мөмкинлекләренә ия. Алар белән мотивлашкан ясалма сүзләрне, иң беренче чиратта, кушымчалау ысулы белән ясалган отсубстантив дериватлар (исем, сыйфат һәм – сирәк кенә – фигыльләр) тәшкил итә. Шунысын әйтергә кирәк: басмага әзерләнгән лексикографик чыганакның тарихи-мәдәни потенциалы аның XV–XVII гасырларда рус лексикасының шактый зур катламын

тәшкил иткән Көнчыгыш фондының үсешен һәм яшәеш үзенчәлекләрен күрсәтү мөмкинлеге белән аңлатыла.

### Чыганаклар

АМГ III – Акты Московского государства, изд. Акад. наук. Разрядный приказ. Московский стол / под ред. Д. Я. Самоквасова. СПб. 1901. Т. 3.

Арс. Сух. Проскинитарий – Проскинитарий Арсения Суханова // Православный палестинский сборник. СПб. 1889. Т. 7. Вып. 3(21).

Каз. ист. – Казанская история 1564–1565 гг./ подгот. текста, вступ. статья и примеч. Г.Н. Моисеевой; под ред. В.П. Адриановой-Перетц. М., Л.: Изд-во АН СССР 1954. 194 с.

Кн. п. Казани – Материалы по истории Татарской АССР: Писцовые книги города Казани 1565–68 гг. и 1648 г. Л.: Изд-во Акад. наук, 1932. XXV, 208 с. (Труды Историко-археографического института. Материалы по истории народов СССР / Акад. наук СССР).

Оруж. Мих. Фед. – Оружие и ратный доспех царя Михаила Феодоровича 1640 года // Савваитов П.И. Описание старинных царских утварей, одежд, оружия, ратных доспехов и конского прибора, в азбучном порядке расположенное. СПб. 1865.

Сл. Каз. кр. XVI – *Исламова Э. А., Галиуллин К. Р.* Казанский край: Словарь памятников XVI в. Казань. 2000. 286 с.

Сл. Мангаз. пам. – Словарь языка мангазейских памятников XVII – первой половины XVIII в. / сост. Н.А. Цомакион. Красноярск: КГПИ. 1971. 581 с.

Сл. Смол. кр. – Региональный исторический словарь второй половины XVII – XVIII в. (по памятникам письменности Смоленского края) / отв. ред. Е.Н. Борисова. Смоленск: Смоленский гос. пед. ун-т, 2000. 367 с.

Х. Котова – Хожение купца Федота Котова в Персию, 1624 г. / публикация Н.А. Кузнецовой. М.: Изд-во вост. лит., 1958. С. 25–60, сп. вт. пол. XVII в.

***Гыйләҗетдинова Гөлинә Хәйретдин кызы,***
*филология фәннәре докторы, профессор, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикография бүлеге фәнни хезмәткәре*

***Гилязетдинова Гелиня Хайретдиновна,***
*доктор филологических наук, профессор, научный сотрудник отдела лексикографии Института языка, литературы и искусства имени Г. Ибрагимова АН РТ*
*ggilaz@mail.ru*